ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендәге 6 пунктында “Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 8 статьяда:
а) 2 өлештә “эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан” сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3 өлештә “эчке эшләр органнары (полиция) яисә башка хокук саклау органнары тарафыннан” сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ 34-ТРЗ